**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

Чернышевский урамы, 23нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

.

**2022 елның 07 декабре** **3052 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Столбище авыл җирлеге, Столбище авылы, Совет ур., 203 йорт. адресы буенча урнашкан территорияне кадастр номеры 16:24:150121:221булган җир кишәрлеген яңадан бүлү юлы белән ызанлау проектын әзерләү турында.**

Территорияләрне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 43, 45 статьялары нигезендә капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына таянып **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Столбище авыл җирлеге, Столбище авылы, Совет ур., 203 йорт. адресы буенча урнашкан территорияне кадастр номеры 16:24:150121:221булган җир кишәрлеген яңадан бүлү юлы белән ызанлау проектын әзерләүгә керешергә.
2. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43 статьясы нигезендә проектның эчтәлеген билгеләргә.
3. Гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) уздыруны исәпкә алып проектны әзерләү срогын 2023 елның 10 маена кадәр билгеләргә.
4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң, физик һәм юридик затларга территорияне ызанлау проекты тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге турында тәкъдимнәрен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә тәкъдим итәргә.
5. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)..

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. П. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.А. Новиков**